ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2026 п.г.т.Алексеевское № 294

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.08.2025 ел, № 369 «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә «Озак һәм актив тормыш» милли проектын гамәлгә ашыру максатында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.08.2025 ел, № 369 «2025-2029 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- программаны җаваплы башкаручылар (1 нче кушымта) «коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләре белән тулыландырырга;
- «I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аның үсешен фаразлау» бүлегенә «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы агымдагы вәзгыятьне бәяләү. 2025 ел башына Алексеевск муниципаль районында халык саны 24480 кеше тәшкил итте, бу Татарстан Республикасы халкының гомуми санының 0,61% тәшкил итә.» сүзләрен өстәргә.

Гендер составы буенча Алексеевск районында хатын-кызлар күбрәк район халкының гомуми саныннан 52% (12730 кеше) тирәсе, димәк, ир-атлар 48% (11750 кеше) тәшкил итә.

Яше буенча эшкә яраклы яшьтәгеләр өстенлек итә, аларга район халкының гомуми санының 57% ы туры килә. Эшкә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр өлеше 23%, эшкә яраклы яшьтән яшьрәкләр 20% тәшкил итә.

Район предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 2025 ел нәтиҗәләре буенча 91968 сум тәшкил итте, 2024 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 17,1% ка артты.

Шул ук чорда эшсезлек дәрәҗәсе 0,05% тәшкил иткән. Республика буенча бу күрсәткеч-0,16%.

Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә зур игътибар бирелә, моның өчен барлык шартлар да тудырылган.

Төп спорт корылмалары: 1 нче «Лидер» спорт комплексы, «Афалина» ябык йөзү бассейны, «Темп» универсаль спорт залы, көрәш залы, чаңгы базасы, «Алекс Арена» боз сарае, «Бадминтон үзәге», Биләр һәм Түбән Тигәнәле авылларындагы спорт комплекслары булу, мәктәпкәчә яшьтәге балалардан башлап һәм дә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә кадәр, спорт белән шөгельләнүгә төрле категориядәге халыкны җәлеп итәргә мөмкинлек бирә.

Районның алга киткән спорт инфраструктурасы бадминтон, футбол, баскетбол, волейбол, хоккей, фигуралы шуу, өстәл теннисы, чаңгы ярышлары, билбау көрәше, иркле көрәш, йөзү, бокс кебек 12 спорт төрен үстерү өчен уңай шартлар тудыра, шулай ук физкультура-сәламәтләндерү чараларына йөрергә дә мөмкинлек бирә.

Районда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү объектлары саны 1000 кешегә исәпләгәндә 953 берәмлекне тәшкил итә.

Районда 2025 елда системалы рәвештә физик культура һәм спот белән шөгыльләнүче халык 68,6% тәшкил иткән.

Алексеевск муниципаль районы Татарстан Республикасының үзәк өлешендә урнашкан һәм аның мәйданы 2074,41 кв. км.

Аксубай, Әлки, Нурлат, Спас, Чистай районнары һәм Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы белән чиктәш.

Район территориясендә сәнәгать, төзелеш тармагы, авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү предприятиеләре эшчәнлек алып бара.

Юл төзелеше өлкәсендә эшчәнлек алып баручы «Алексеевскдорстрой» ААҖ бюджет булдыручы предприятиесе әһәмиятле.

Районда сәнәгать түбәндәге предприятиеләрдән тора: төзелеш кирпече җитештерү буенча «Алексеевск керамикасы» ААҖ, «Алексеевск нәфис туку фабрикасы» ҖЧҖ рус һәм татар халык стилендә уникаль эшләнмәләр чыгара, «Алексеевск сөт заводы» ҖЧҖ сөт продукциясе чыгара.

«Мостовик» ҖЧҖ предприятиесе 50 төрдән артык кагу свайлары, 30 маркада бетон, 50 төр ТБЭ җитештерә.

«ТатМаш» заводы асфальт-бетон заводлары һәм аларга запас частьләр җитештерә.

«Агро-лидер» ҖЧҖ көнбагыш мае җитештерү куәте тәүлеккә 150 тонна булган завод.

«Алексеевск кабель заводы» ҖЧҖ төрле кисемтәле кабель чыгара.

Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, нигездә, ит-сөт юнәлешле һәм бөртеклеләр үстерү белән шөгыльләнәләр - болар: «Алексеевск ХП», «Родина» колхозы, «Алга «Колхозы» ҖЧҖ, «КВ Агро»АҖ бүлекчәләре.

2025 ел йомгаклары буенча алкоголь продукциясен ваклап сатуга лицензиясе булган сәүдә объектлары белән тәэмин ителеш районда 1000 кешегә исәпләгәндә 4,5 берәмлек тәшкил итә. Тулаем республика буенча бу күрсәткеч 1,9 берәмлек тәшкил итә».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Алексеевск муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**